**ГЛАВА**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 Балык Бистәсе штп. № 188пг

Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган коррупциягә каршы чаралар үткәрү турында

Коррупциягә каршы шартлар тудыру, җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп тормаслык мөнәсәбәт формалаштыру, коррупциягә каршы көрәшне активлаштыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы активлаштыру, кадрларны, матди, мәгълүмати һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү максатында, Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 29 июнендә 378 номерлы Указы белән расланган 2018-2020 елларга коррупциягә каршы торуның Милли (илкүләм) планы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган “2015-2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру” дәүләт программасы (2019 елның 16 сентябрендәге үзгәрешләр белән) һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган “2015-2022 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру” муниципаль программа (2019 елның 16 сентябрендәге үзгәрешләр белән) нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 2019 елның 1 декабреннән 9 декабренә кадәр Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар комплексын уздырырга.

2. Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар планын (алга таба - План) расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Район учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләренә Планда каралган чараларны әзерләүне һәм үткәрүне оештырырга тәкъдим итәргә.

4. “Авыл офыклары” район газетасында коррупциягә каршы чараларны яктыртуны тәэмин итәргә.

5.Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесенә 2019 елның 15 декабренә кадәр үткәрелгән чаралар турында тулы мәгълүмат тапшырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

И.Р. Таҗетдинов

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар планы**

| №<br>п/п | Чараның исеме | Җаваплы башкаручы | сроклары | искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Коррупциягә каршы тематика буенча ачык дәресләр, сыйныф сәгатьләре үткәрү | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ | мәгариф оешмалары планы буенча | |
| 2. | Стендлар, тематик китап күргәзмәләре, стенгазеталар чыгару, коррупциягә каршы юнәлештәге рәсемнәр конкурсы оештыру: “Коррупция-хокук бозуның аерым төре буларак”, “Дәүләт һәм хокук”, "Син законны беләсеңме?” “Коррупция-Стоп», " Балык Бистәсе районы коррупциясез территория” | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ, “Социаль-мәдәни өлкә бүлеге” МКУ, “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 18.06.19 941/19 номерлы боерыгы буенча<br><br>2019елның 30сентябренә кадәр | |
| 3. | Өлкән сыйныф укучыларының "Коррупция - юк!" темасына хокук саклау органнары вәкилләре белән очрашуларын оештыру | Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ, ” Агротехник техникум” ДАҺБУ ”Форпост” | декабрь 2019 ел | |
| 4. | “Яшьләрнең хокукый культурасын формалаштыру - җәмгыятьтә коррупциягә каршы үз-үзеңне тоту нигезе”, “Хокук тәрбиясе. Балигъ булмаганнарның хокуклары һәм җинаять җаваплылыгы” | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ | мәгариф оешмасы планы буенча | |
| 5. | Авыл җирлекләрендә “Балык Бистәсе районы – коррупциядән азат территория” шигаре астында коррупциягә каршы юнәлештәге чаралар оештыру һәм үткәрү | Балык Бистәсе муниципаль районының авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлеге башлыклары | | |
| 5.1 | "Без тынычлык өчен – коррупциядән башка" хокукый мәгълүмат сәгате | Клуб мөдире | 09.12.2019 | |
| 5.2 | “Без коррупциягә каршы” акциясе | Мәдәният йорты директоры | 11.12.2019 | |
| 5.3 | “Коррупциягә ЮК дип әйт" мәгълүмати-иллюстрацияле күргәзмәләр | Авыл китапханәсе мөдире | 09.12.2019-19.12.2019 | |
| 5.4 | Авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында коррупциягә каршы көрәшне хокукый тәэмин итү һәм | Авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе | 06.12.2019-16.12.2019 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | коррупциягә каршы үз-үзеңне тоту стандартлары буенча мәгълүмат урнаштыру | | | |
| 5.5 | “Коррупциягә каршы бергә” дигән аралашу сәгате: “Тормышның үз кагыйдәләре бар” | Авыл җирлеге Башлыгы | 10.12.2019 | |
| 5.6 | "Без тынычлык өчен – коррупциядән башка" хокукый мәгълүмат сәгате | Клуб мөдире | 09.12.2019 | |
| 6. | “Илемнең киләчәге - минем кулда” район иншалар конкурсын үткәрү | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы “Мәгариф бүлеге” МКУ | Мәгариф һәм фән министрлыгының 18.06.19 941/19 номерлы боерыгы буенча<br>2019елның 30сентябренә кадәр | |
| 7. | “Кулларга тотыныйк, дуслар”исемле спорт чарасы үткәрү | “Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлеге” МКУ | 13.12.2019 | |
| . | Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча үткәрелә торган эшне гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгару | “Татмедиа” АҖ нең “Авыл офыклары” район газетасы | 2019 елның 15 октябрен нән 7 декабренә кадәр | Район халкына газета, сайт, социаль челтәрләр аша алда торган Халык ара коррупциягә каршы көрәш көне турында хәбәр итү, бу көнгә багышланган чаралар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | дан статья лар һәм планлы мәкалә ләр басты рып чыгару |
| 9. | "Стоп коррупция”акциясе. Буклетлар тарату юлы белән халыкка мәгълүмат, хәбәр ирештерү | “Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музее” МБУ | 9 декабрь | |
| 10. | Стендлар бизәү, Агротехник техникум студентлары арасында коррупциягә каршы юнәлештәге плакатлар конкурсы оештыру: “Коррупция-хокук бозуның аерым төре буларак”, “Дәүләт һәм хокук”, “Син законны беләсеңме?”, “Коррупция-СТОП” | “Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлеге” МКУ | 2-8.12.2019 | |
| 11. | «Форпост» отрядының Агротехник техникумы студентлары катнашында "Рәхмәтме яки ришвәтме, чик кайда?"темасына түгәрәк өстәл. Ролик күрсәтү | “Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм буенча бүлеге” МКУ, “Форпост” | 09.12.2019 | |